ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАРЫ

№ 7 от 02.11. 2022 г

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино
авыл җирлегенең Батыр торак пунктында
гражданнарның үзара салымнарын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 11 ноябрендә 9 сәгать 30 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Батыр торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Тимошкино авыл җирлеге Батыр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә , моннан тыш, 1 төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Украинадагы махсус операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаиләләреннән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала; Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

**1. Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
**- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен шартнамә буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;**
**2. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);**

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Аксубай районы Батыр авылының 3 нче йорты адресы буенча урнашкан йорт янында халык җыены үткәрергә.

**4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, стендларда һәм белдерү такталарында эленү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк.**

**5.Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.**

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы : П.А.Мулеева